**ГЛАВА КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**27 март 2026 ел** **№ 1**

**Кадастр номеры 16:16:220101:67 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы проект буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Кешенең тормыш эшчәнлегенең уңайлы шартларына хокукын саклау, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Красносельский авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 22 мартындагы 116 нчы номерлы (2021 елның 28 апрелендәге 25 нче номерлы, Совет карары редакциясендә) карары белән расланган Красносельский авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге территориясендә кадастр номеры 16:16:220101:67, мәйданы 1427 кв.м. булган җир кишәрлегенең Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Красносельский авыл җирлеге, Биектау тимер юл станция поселогы, Чернышевский урамы, 15 адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең «Кунакханә хезмәте күрсәтү» аз катлы күп фатирлы торак төзелеше зонасында (Ж2) файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы проект буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны үткәрү датасын, вакытын һәм урынын расларга:
үткәрү вакыты һәм датасы: 2026 елның 7 апреле 9 сәгать 00 минутта.
үткәрү урыны: Биектау тимер юл станция поселогы, Чернышевский урамы, 15, кадастр номеры 16:16:220101: 67.

3. Әлеге карар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруга һәм уздыруга вәкаләтле орган түбәндәге составтагы оештыру комитеты була:

- Нуруллин Р.Ф. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе;
- Хисамутдинов Р.Ш. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары (килешү буенча);
- Марданшина А.Х. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитетының әйдәүче белгече;
- Хакимов И.И. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы депутаты;
- Никитенко Р.Р. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башлыгы урынбасары.

4. Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр 2026 елның 7 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан җирле үзидарә органының эш режимы нигезендә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станция поселогы, Мәктәп урамы, 17 нче йорт (Биектау муниципаль районы авыл хуҗалыгы идарәсе бинасы, 2 нче кат, Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бүлмәсендә) язма рәвештә һәм гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында язмача яисә телдән кабул ителә.

5. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Карар проекты белән Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Мәктәп урамы, 17 йорт адрес буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә танышырга мөмкин.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов